

Яз башы, бик капризлы булуга карамастан, елдагыча булмаса да, хужалыкларда козге культуралар һәм күпьеллыкларга ашлама кертү, тырмалау, чәчүлек орлыкларны торле авыруларга каршы препаратлар белән эшкәртү үткәреп чәчү эшләре бетеп бара. Әмма Мордовиянен конбатыш районнарында ужымнын начар хәле борчый. Ужым сыйфатын космос аша тошерүләр аша күзәтеп баралар. Быел ужымнын кышлавы, үткән елга караганда, 30% начар. Вакытлыча Мордовия Главасы бурычларын башкаручы Владимир Волков: «Для того, чтобы не получить урожайность 15-18 центнеров с гектара, нам необходимо пересеять озимые на площади 12 тысяч гектаров», - ди авыл хужалыгы һәм азык-толек министры Владимир Сидоров белән очрашканда.

Яз башы чәчүенә килгәндә, кайбер аграриилар яз башы чәчү эшләрен тәмамлады. Мәсәлән, Саранск шәһәре Октябрь районы жирләрендә 4 мен гектар жирдә яровой бертеклеләрне чәчкәннәр. Шул исәптән бодай – 1514 га, арпа - 2409 га, борчак - 5 га, солы - 15 га, вика - 5 га, карабодай – 7 га. Тагы 105 га жиргә яшелчәләр (суган - 21 га, кишер - 16 га, чогендер – 11 га, кәбестә – 55 га, кабачки – 4 га) утыртканнар. Кормовойлардан - 916 га силоска кукуруза, 400 га кукурузны орлыкка, 707 га берьеллык үләннәр, 636 га жирдә күпъеллык үлән чәчеп бетергәннәр.

Торбеево районы ООО «Юнки»нын алга карап эш итүче житәкче Раис Равиль улы Салихметов та кыр эшләрен тәмамлаган. 450 гектар ужымнары да үзләрен яхшы хис итә: арышы әйбәт кышлаган, ә бодае анардан бераз калыша. Башта жилләр туфракны киптергән иде, әлеге янгырлар вакытында яуды, бераз салкынрак кына, ди Раис Равиль улы Салихметов. 250-330 тонна бик әйбәт орлык фонды анын булган, әмма ашламалары гына аз. 35% ашламаланган 400га арпа, 200га вика, 50га берьеллык үләнне чәчкәннәр. 150 гектар кукурузаны тулы житәрлек ашлама (ана бүлеп калдырган булганнар) белән чәчкәннәр.

Раис Равиль улы белән алдагы ел да алган интервьюда техникаларынын ватылып килүе борчыганын ишеттем. Дүрт ел элек бер комбаин һәм МТЗ 1241алган булсалар, бүген аларны һәм тагы да искерәкләрен ремонтлап эш итәләр. Ягулыкны сотләрен саткан акчага алалар. Ут һәм ягулыкнын бәяләре арта бара, дигәне борчый аны. Быел, алдагы еллар тосле, 800-900 мен сум субсидия ала алмаганнар, чонки налогларынын барысын да вакытында түләргә акчалары житмәгән. Әмма ул оптимист, унышны гектарыннан 23 центнер алырга планлаштыра. Тулы күләмдә ашлама керткән вакытта утыздан да артыгын урып жыйганнар. Күбрәк Татар Йонә халкы хезмәт итә хужалыгында, комбайнерлары күрше Зур Ивановка авылыннан. Кон саен чәчү эшләре

башкарып чыгу жинел тvгел. Монын очен булган кадәр техниканы тиешенчә файдалану гына тvгел, ә чәчvдә катнашучы һәр белгеч, механизатор, игенченен хезмәтен дорес итеп оештыру, хужалыклардагы эчке момкинлекләрне эшкә жигv кирәк.
Тулаем алганда, республикабызда эшләр план буенча бара: 70% бертекле культуралар һәм 70% артык кукуруза чәчкәннәр инде. Ужымнарны, кvпьеллык vлән нәрне тукландыру, тырмалау эше дәвам итә. Хезмәтчәннәргә унышлар телибез.
Владимир Волков: «Все работы производятся на высоком уровне, на полях работает много молодых высококвалифицированных специалистов, которые грамотно выполняют свою задачу. На поля внесено на 10 тонн удобрений больше, чем в прошлом сезоне», - ди MordovMedia.ru сайтында.
Шокер, Мордовия буенча язгы чәчvгә әзерлек тә начар дип әйтерлек тvгел. Kvп хужалыклар ягулык-майлау материаллары, запас частьлар, орлык, ашлама, башка кирәк-яракларны туплаган. Мордовия Авыл хужалыгы һәм азык-толек министрлыгыннан алынган мәгълvматларга караганда, язгы кыр эшләренен һәр юнәлешендә vзенә кvрә алдынгылар да ачыклана.

Н.Хәлил